**“Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре” 22 август, 2007 ел, № 407**

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары**

**(4 август, 22 декабрь, 2008 ел; 3 июнь, 30 сентябрь, 2009 ел; 19 июль, 18 октябрь, 17 декабрь, 2010 ел; 14 февраль, 2011 елгы үзгәрешләр белән)**

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары структурасы турында” 28.04.2005 ел, № УП-147 Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәне һәм аның структурасын (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы хезмәткәрләренең чик санын 136 берәмлек күләмендә, вазыйфаи окладлар буенча хезмәткә түләүнең айлык фондын 587,6 мең сум күләмендә билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына министрның өч урынбасарын, шул исәптән бер беренче урынбасарын булдыруны рөхсәт итәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын үз көчен югалткан дип танырга.

“Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре” 6 июль, 2005 ел, № 324;

“Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре” 06.07.2005 ел, № 324 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында” 29 декабрь, 2005 ел, № 662;

“Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре” 06.07.2005 ел, № 324 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында” 17 апрель, 2006 ел, № 191;

“Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре” 06.07.2005 ел, № 324 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында” 21 апрель, 2006 ел, № 205.

5. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуның Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**

**Премьер-министры Р.Н.Миңнеханов**

**“Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында**

**НИГЕЗЛӘМӘ**

**(22 август, 2007 ел, № 407 ТР МК карары белән расланды)**

**(19 июль, 17 декабрь, 2010 елгы үзгәрешләр белән)**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – Министрлык):

республикада җир һәм милек мөнәсәбәтләре өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен алып баручы;

Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт һәм җир ресурслары белән идарә итү буенча, шул исәптән хосусыйлаштыру һәм эш итү буенча милекче вәкаләтләрен башкаручы республика башкарма хакимияте органы булып тора.

1.2. Министрлыкның идарә системасына дәүләт унитар предприятиеләре (алга таба – дәүләт предприятиеләре), дәүләт учреждениеләре керә.

1.3. Министрлык, үз компетенциясе чикләрендә, оештыру-хокукый формаларына һәм теге яки бу ведомство карамагында булу-булмауларына бәйле рәвештә, бу Нигезләмәгә кушымтада күрсәтелгән эшчәнлек төрләре буенча билгеләнгән тәртиптә оештырылган предприятиеләр, учреждениеләр һәм башка оешмалар белән берлектә эшли.

1.4. Министрлык, үз компетенциясе чикләрендә һәм күләмнәрендә федераль дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм башка оешмалар белән берлектә үзенең эшчәнлеген алып бара.

1.5. Министрлык үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарларына, Россия Федерациясе Президенты, Татарстан Республикасы Президенты указларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына һәм боерыкларына, дәүләтара һәм хөкүмәтара килешүләргә, шартнамәләргә, Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булып килүче башка норматив-хокукый актларга, шулай ук бу Нигезләмәгә таяна.

1.6. Министрлык юридик зат булып тора, аның мөстәкыйль балансы, банк учреждениеләрендә расчет счеты һәм башка счетлары (валюта счетын

кертеп), үзенең атамасы һәм Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәте белән мөһере, штамплары бар.

1.7. Министрлык Татарстан Республикасы Дәүләт милке белән идарә итү буенча дәүләт комитетының хокукый дәвамчысы булып тора.

1.8. Министрлыкның урнашу урыны (юридик адресы): 420043, Татарстан Республикасы, Казан ш., Вишневский ур., 26 й.

**2. Министрлыкның бурычлары**

Министрлыкның төп бурычлары булып тора:

2.1. Җир һәм милек мөнәсәбәтләре өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру, Татарстан Республикасы дәүләт милкен хосусыйлаштыру.

2.2. Татарстан Республикасы дәүләт милкеннән файдалануның максималь дәрәҗәдә нәтиҗәлелеген һәм керем китерүен тәэмин итү.

2.3. Татарстан Республикасы дәүләт милкен һәм җир ресурсларын Татарстан Республикасы икътисадына инвестицияләр җәлеп итү чарасы сыйфатында куллану.

**3. Министрлыкның вазыйфалары**

3.1. Министрлык түбәндәге вазыйфаларны тормышка ашыруга җавап бирә:

Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт белән идарә итү (01.07*);

Татарстан Республикасы милкендәге күчемсез мөлкәттән (биналар, корылмалар), транспорт, җиһазлар, мәдәни мирас объектларыннан файдалануны идарә итү (01.07.01*);

Татарстан Республикасы милкендәге акцияләр (өлешләр) пакетыннан файдалануны идарә итү (01.07.02*);

Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне билгеләнгән тәртиптә хосусыйлаштыруны идарә итү (01.07.03*);

Татарстан Республикасы милкендәге оешмаларны, биналарны, корылмаларны, транспортны, җиһазларны, акцияләрне (өлешләр) билгеләнгән тәртиптә хосусыйлаштыруны идарә итү (01.07.03.1*);

Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен билгеләнгән тәртиптә хосусыйлаштыруны идарә итү (01.07.03.2*);

Татарстан Республикасы җир ресурслары белән идарә итү (01.07.04*);

җирләрне билгеләнгән тәртиптә категорияләргә кертүне, аларны бер категориядән икенчесенә күчерүне (Татарстан Республикасы милкендәге җирләргә, шулай ук муниципаль милектәге һәм шәхси милектәге авыл хуҗалыгы максатындагы җирләргә карата) идарә итү (01.07.04.1*);

Татарстан Республикасы милкендәге җир ресурслары белән идарә итү (01.07.04.2*);

3.2. Министрлык үз компетенциясе чикләрендә берлектә эшли:

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән, түбәндәге вазыйфаларын хәл итүдә:

социаль-икътисадый программалау (01.01.*);

Татарстан Республикасы территориаль планлаштыру схемасын һәм территориаль планлаштыру схемасын тормышка ашыру планын эшләүне тәэмин итү (01.05.1*);

инвестицион эшчәнлекне үстерүне идарә итү (01.10*);

инновацион эшчәнлекне үстерүне идарә итү (01.11*);

Татарстан Республикасы ведомстволарының дәүләт мәгълүмати ресурсларын булдыруны идарә итү (01.15.01.2*);

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән, түбәндәге вазыйфаларын хәл итүдә:

энергияне һәм ресурсларны сак тотуны идарә итү (01.14*);

сәнәгать белән идарә итү (03.01*);

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән түбәндәге вазыйфаларын хәл итүдә:

бюджет процессын (Татарстан Республикасы бюджеты һәм бюджеттан тыш дәүләт фондлары) идарә итү (01.02.1*);

бюджетара мөнәсәбәтләрне җайга салу (01.02.3*);

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән, торак базарлары булдыруга шартлар тудыру; торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен шартлар тудыру вазыйфаларын хәл итүдә (04.01.01*);

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән – Татарстан Республикасы янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүне идарә итү вазыйфаларын хәл итүдә (02.01.03*);

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм Элемтә министрлыгы белән – Татарстан Республикасы дәүләти мәгълүмат системаларын үстерүне идарә итү (дәүләт мәгълүмати ресурсларын булдыруны идарә итүдән тыш) вазыйфаларын хәл итүдә (01.15.02*);

Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитеты белән – социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат ресурсларын булдыруны идарә итү вазыйфаларын хәл итүдә (01.15.01.1*).

3.3. Министрлык үз компетенциясе чикләрендә һәм бу Нигезләмәнең 3.1 һәм 3.2 пунктлары нигезендә түбәндәге вәкаләтләрне хәл итә:

3.3.1. Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт һәм җир ресурслары белән идарә итү стратегиясен билгеләүдә катнаша. Татарстан Республикасы милкендәге структураны, Татарстан Республикасы күчемсез милкенең сан һәм сыйфат ягыннан составын (шул исәптән җир ресурслары күләмен) оптимальләштерү чараларын күрә.

3.3.2. Базарларның (фонд, күчемсез милек һәм җир базарлары) торышын, шулай ук Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт һәм җир ресурсларын хосусыйлаштыруга, идарә итү, файдалану, алар белән эш итүгә бәйле процессларны анализлый һәм алынган мәгълүматлар нигезендә, икътисадның нәтиҗәлелеген һәм социаль юнәлешле булуын көчәйтү

максатыннан чыгып, мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләрен реформалау ысулларын камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшли.

3.3.3. Татарстан Республикасы министрлыклары белән берлектә, билгеләнгән тәртиптә, бу Нигезләмәгә кушымтада күрсәтелгән эшчәнлек төрләрен кризиска каршы үстерү буенча республика максатчан программаларын, шулай ук кризиска каршы идарә мәсьәләләре буенча башка хокукый актлар проектларын эшли һәм тормышка ашыра.

3.3.4. Татарстан Республикасы исеменнән, билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт белән, шул исәптән җир кишәрлекләре белән идарә итә, алардан файдалана һәм алар белән эш итә.

3.3.5. Закон нигезендә Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне арендага бирү, залогка тапшыру, ышаныч нигезендә идарәгә, бушлай файдалануга тапшыру һәм файдалануның башка формалары турында, шулай ук концессион карарлар нигезендә Татарстан Республикасы милкендәге объектларга ия булу һәм алардан файдалану хокуклары бирү турында карарлар кабул итә.

3.3.6. Закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне һәм җир кишәрлекләрен сатучы вазыйфаларын башкара. Махсус оешмалар белән сатулар (конкурслар, аукционнар) үткәрү турында килешүләр төзи.

Махсус оешмаларга, сату өчен, билгеләнгән тәртиптә хосусыйлаштыру объектларын тапшыра.

3.3.7. Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрын алып бара һәм аның кысаларында Татарстан Республикасы милкендәге җирләрнең учетын алып бара, Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне һәм җир ресурсларын учетка алу системасы эшен тәэмин итә, Татарстан Республикасы милкендәге күчемсез һәм күчемле мөлкәтнең булуы турында һәм аннан файдалану турында мәгълүматның тулылыгын һәм дөреслеген тәэмин итә.

3.3.8. Татарстан Республикасы милкендәге күчемсез милек буенча бердәм мәгълүмат системасын, шулай ук Министрлыкның эшчәнлеге юнәлешләре буенча башка автоматлаштырылган мәгълүмат системаларын булдыруны һәм аларның эшләвен тәэмин итә.

3.3.9. Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен һәм башка милекне, шулай ук дәүләт предприятиеләрен, дәүләт учреждениеләрен мөлкәт комплекслары буларак федераль милеккә, Россия Федерациясе субъектлары милкенә, муниципаль милеккә тапшыруны хәл итә.

3.3.10. Закон нигезендә билгеләнгән очракларда Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен һәм башка мөлкәтне физик һәм юридик затлар милкенә тапшыруны хәл итә.

3.3.11. Федераль милектәге, Россия Федерациясе субъектлары милкендәге, муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен һәм башка мөлкәтне Татарстан Республикасы милкенә кабул итүне хәл итә.

3.3.12. Закон нигезендә билгеләнгән очракларда дини максаттагы Татарстан Республикасы дәүләт милкен дини оешмаларга милеккә бушлай тапшыруны хәл итә.

3.3.13. Чикләүләре булмаган физик һәм юридик затлар милкендәге мөлкәтне, шул исәптән җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы милкенә бушлай кабул итә.

3.3.14. Федераль законда билгеләнгән тәртиптә күчемсез милеккә, шул исәптән җир кишәрлекләренә Татарстан Республикасы милек хокукын дәүләт теркәвенә алу буенча чаралар оештыра.

3.3.15. Күчемсез милек һәм җир базарында профессиональ катнашучылар (бәяләүчеләр, җир белән эш итү, риэлтор оешмалары һәм башка оешмалар) эшчәнлеген закон кысаларында җайга салуда катнаша.

Тиешле үзкөйләнешле оешмалар (бәяләүчеләр, сервейерлар, риэлторлар, арбитраж идарәчеләр гильдияләре, аудиторлык фирмалары ассоциациясе, төзүчеләр, техник инвентарьлаштыру, җирне ызанлау һәм үлчәү, күчемсез милекне һәм җир кишәрлекләрен сату белән шөгыльләнүче структуралар) белән, уртак киңәшмә һәм эксперт органнары (советлар, комиссияләр, төркемнәр) төзү нигезендә, конференцияләр, семинарлар оештырып, шулай ук гомуми кагыйдәләр, эшчәнлек стандартларын булдыруда, берлектә эшли.

Устав капиталларында Татарстан Республикасы өлеше кимендә 25 процент тәшкил иткән хуҗалык итүче җәмгыятьләрнең аудиторларын сайлап алу буенча конкурслар үткәрүне оештыра.

Эшмәкәрлеккә ярдәм итү чараларын күрә, консалтинг, мәгълүмат системаларын һәм күчемсез милек һәм җир белән идарә итү өлкәсендә башка хезмәт күрсәтүләр системасын үстерүгә ярдәм итә, шул исәптән Татарстан Республикасы катнашында күчемсез милек базарының үтәкүренмәлелеген һәм ачыклыгын тәэмин итүче махсус мәгълүмати системалар һәм интернет-ресурслар булдыру юлы белән.

3.3.16. Кадастр инженерларына карата куела торган квалификация таләпләренә туры килүгә аттестация үткәрү өчен квалификация комиссиясе булдыра һәм аның эшен оештыра.

Кадастр инженерларына карата куела торган квалификация таләпләренә туры килүгә аттестация үткән затларга квалфикация аттестатлары тапшыра.

3.3.17. Беренчел һәм икенчел җир базарларын үстерү буенча дәүләт сәясәтен тормышка ашыруны тәэмин итә. Җир базары инфраструктурасын үстерүдә катнаша, шул исәптән махсус оешмаларга, физик һәм юридик затларга җир кишәрлекләренә хокукларын тормышка ашыруда, җир кишәрлекләре буенча аукционнар үткәрүдә консультация ярдәме күрсәтә.

3.3.18. Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләре белән эш итү турында, шул исәптән билгеләнгән тәртиптә җир кишәрлекләре бирү:

Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, дәүләт хакимияте органнарына даими (сроксыз) файдалану хокукында, шулай ук башка

хокукларда – дәүләт предприятиеләренә, дини оешмаларга һәм башка оешмаларга;

әлеге җир кишәрлекләрендә урнашкан биналарны, корылмаларны, милеккә яки арендага бирү;

Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтнең урнашкан җир кишәрлекләрен, аларны хосусыйлаштырганда яки арендага тапшырганда бирү;

авыл хуҗалыгы максатындагы җирләрдән крестьян (фермер) хуҗалыгын, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен җир кишәрлеге бирү турында карарлар кабул итә;

3.3.19. Закон нигезендә авыл хуҗалыгы максатындагы җирләрдән җир кишәрлекләрен сату турында милекчеләрнең извещениеләрен карап тикшерә, билгеле бер җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы милкенә сатып алу турында, шулай ук сатып алудан баш тарту турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларын әзерли.

3.3.20. Татарстан Республикасында җирләрнең дәүләт резервын формалаштыруда катнаша һәм Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җирләрне резервлау чараларын күрә.

3.3.21. Закон нигезендә билгеләнгән очракларда җир кишәрлекләре бирү турында, шул исәптән элегрәк Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыру процессында оештырылган акционерлык җәмгыятьләренә бирелгән җир кишәрлекләре белән, шулай ук Казан шәһәре территориясе чикләрендә Татарстан Республикасында җирләрнең дәүләт резервына кертелгән җир кишәрлекләре белән эш итү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларын әзерли һәм җир кишәрлекләрен сатудан һәм арендага бирүдән кергән средстволарның Татарстан Республикасы бюджетына алынуына контрольлек итә.

3.3.22. Закон нигезендә күздә тотылган очракларда Татарстан Республикасы милкендәге җирләрдән җир кишәрлекләрен арендалау хокукын, җир кишәрлекләреннән билгеле бер вакыт эчендә бушлай файдалану хокукын мәҗбүри төстә туктату турында карарлар кабул итә.

3.3.23. Социаль ипотека программасын тормышка ашыру кысаларында торак төзелеше өчен җир кишәрлекләрен бирүне тәэмин итә.

3.3.24. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, җир кишәрлекләрен, шулай ук башка мөлкәтне Татарстан Республикасы милкенә сатып ала, Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен билгеләнгән тәртиптә тартып алынган җир кишәрлекләрен сатып ала.

3.3.25. Җир кишәрлекләрен авыл хуҗалыгы максатындагы җирләрдән башка категориягә күчерү турында үтенечнамәләрне карап тикшерә, һәм җир кишәрлекләрен авыл хуҗалыгы максатындагы җирләрдән башка категориягә күчерү турында, җир кишәрлекләрен торак пунктлар чикләренә кертү турында яисә җир кишәрлекләрен авыл хуҗалыгы максатындагы җирләрдән башка категориягә күчерүдән баш тарту турында, җир кишәрлекләрен торак

пунктлар чикләренә кертүдән баш тарту турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының хокукый актлары проектларын әзерли.

Җирләрне бер категориядән башкасына күчерү турында мәгълүмат җыя һәм гомумиләштерә.

3.3.26. "Авыл хуҗалыгы максатындагы җирләрнең әйләнеше турында" Федераль законда күздә тотылган очракларда һәм тәртиптә тиешле гаризалар белән судка мөрәҗәгать итә.

3.3.27. Үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләре белән идарә итүгә һәм җир реформасын үткәрүгә бәйле эшләрнең дәүләт заказчысы була, закон нигезендә, аларны үтәүгә заказлар урнаштыра.

3.3.28. Закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә оештырыла торган дәүләт предприятиеләренең гамәлгә куючысы була.

Дәүләт предприятиеләре уставларын раслый.

Дәүләт предприятиеләренең устав фондын булдыра, үзгәртә, шулай ук аларның резерв фондларыннан һәм башка фондларыннан файдалануга контрольлек итә.

3.3.29. Дәүләт предприятиеләренең, шул исәптән хосусыйлаштыру процессына җәлеп ителгән дәүләт предприятиеләренең (икътисад тармаклары буенча), аларның санын оптимальләштерү һәм көндәшлеккә сәләтен арттыру максатыннан чыгып, эшчәнлегенең икътисадый нәтиҗәлелек күрсәткечләрен анализлый.

Дәүләт предприятиеләренә аудиторлык тикшерүләре үткәрү турында карарлар кабул итә һәм аларның аудиторларын раслый, тармак компетенциясендәге Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тәкъдимнәреннән чыгып, билгеләнгән тәртиптә аудиторлык оешмаларының хезмәтләр күрсәтүенә түләү күләмен билгели.

3.3.30. Дәүләт предприятиеләренә үзләренең уставта каралган бурычларын үтәү өчен кирәкле милекнең оптималь күләмен билгели.

Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне дәүләт предприятиеләренә хуҗалык алып бару хокукында билгели.

3.3.31. Дәүләт предприятиеләренә билгеләнгән тәртиптә ризалык бирә:

күчемсез милекне тартып алуга һәм аның белән башкача эш итүгә, шул исәптән залогка, арендага, мөлкәти керемнәрне оешмаларның устав (җыелма) капиталларына (фондлар) кертү, шулай ук федераль законнарда, башка норматив-хокукый актларда яки дәүләт предприятие уставында күздә тотылган очракларда – бүтән алыш-бирешләр ясауга;

"Дәүләт предприятиеләре һәм муниципаль предприятиеләр турында" Федераль законда билгеләнгән очракларда зур алыш-бирешләр һәм кызыксыну тудырган алыш-бирешләр ясауга;

займнар бирү, поручительлек, банк гарантияләре алу, башка чикләүләр бурычлар, таләпләрне киметү, бурычны күчерү, шулай ук гади ширкәт килешүләрен төзү белән бәйле алыш-бирешләр ясауга;

дәүләт предприятиесенең башка юридик затларда катнашуына;

дәүләт предприятиесе филиалларын булдыруга һәм вәкиллекләрен ачуга.

Дәүләт предприятиеләренә займнар күләмен һәм җәлеп ителә торган средстволардан файдалану юнәлешләрен килештерә.

3.3.32. Дәүләт предприятиеләре, шул исәптән социаль әһәмиятле дәүләт предприятиеләре хәлен анализлау, мониторинг ясау һәм фаразлау өчен кирәкле мәгълүматлар базасын кертү буенча координатор вазыйфасын башкара.

3.3.33. Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне дәүләт учреждениеләренә оператив идарә хокукында билгели, шулай ук билгеләнгән тәртиптә оператив идарә хокукында билгеләнгән кирәгеннән артык, файдаланылмый торган яки билгеләнеше буенча файдаланылмый торган милекне тартып ала.

Дәүләт учреждениеләре уставларын килештерүне хәл итә.

3.3.34. Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә автоном учреждениеләр мөлкәте белән алыш-бирешләрне килештерә, автоном учреждениеләрнең күзәтчелек советларына кандидатуралар тәкъдим итә.

3.3.35. Дәүләт предприятиеләренә, дәүләт учреждениеләренә закон нигезендә билгеләнгән хокукларда билгеләнгән, шулай ук башка затларга билгеләнгән тәртиптә тапшырылган Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләре һәм башка мөлкәт белән идарә итүгә, файдалануга, эш итүгә контрольлек итә һәм бозулар ачыкланганда закон нигезендә бозуларны юкка чыгару өчен һәм гаепле затларны җаваплылыкка тарту өчен кирәкле чаралар күрә.

3.3.36. Үз компетенциясе чикләрендә, Татарстан Республикасы милкендәге объектларга инвентарьлаштыру билгели һәм үткәрә, Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәттән нәтиҗәле файдалану һәм аны саклау мәсьәләләре буенча юридик затларга документаль тикшерүләр һәм башка тикшерүләр билгели һәм үткәрә.

3.3.37. Дәүләт предприятиеләренә – хуҗалык итү хокукында, дәүләт учреждениеләренә – оператив идарә хокукында билгеләнгән;

шәхси милек формасындагы оешмаларга һәм хосусый эшмәкәрләргә бушлай файдалануга, арендага, ышаныч нигезендә идарә итүгә, концессия нигезендә һәм башка хокукый нигезләрдә тапшырылган төп фондларның гамәлдән алынуын хәл итә һәм контрольдә тота, шулай ук туктатылган һәм (яки) хәл ителмәгән объектлар төзелешенә чыгымнарны контрольдә тота.

3.3.38. Концессион механизмнар, ышаныч нигезендә идарә итү, инвестицияләү нигезендә юл һәм торак-коммуналь хуҗалык объектларын реконструкцияләүгә һәм модернизацияләүгә шәхси инвесторлар средстволарын җәлеп итә.

3.3.39. Татарстан Республикасы дәүләт милкен капитализацияләү, инвестицион эшчәнлек алып бару өчен Татарстан Республикасы милкендәге

күчемсез милек объектларын бирү, шул исәптән җир кишәрлекләрен бирү турында карарлар кабул итә.

3.3.40. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең кызыксынулы органнары белән килешенеп, дәүләт предприятиеләренә карата карарлар кабул итә, шул исәптән дәүләт предприятиеләрен үзгәртеп оештыру, бетерү, бөлгенлек процедураларын башлап җибәрү турында. Закон кысаларында, устав капиталларында Татарстан Республикасы өлеше булган акционерлык җәмгыятьләренә карата бөлгенлек процедураларын башлап җибәрүне тәэмин итә һәм аларны үткәрүгә контрольлек итә.

Федераль законнар нигезендә устав капиталларында Татарстан Республикасы өлеше булган дәүләт предприятиеләрен, акционерлык җәмгыятьләрен судтан тыш бетерү процедураларын оештыра һәм бу процедураларны үткәрүгә контрольлек итә.

3.3.41. Устав капиталларында Татарстан Республикасы өлеше булган дәүләт предприятиеләренә һәм акционерлык җәмгыятьләренә карата кризиска каршы идарә чараларын, бөлгенлеккә төшүне кисәтү чараларын эшли һәм тормышка ашыра.

3.3.42. Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне тиешле елга хосусыйлаштыруның фараз планы (программа) проектын эшли һәм анык билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшыра.

3.3.43. Дәүләт предприятиеләрен, Татарстан Республикасы милкендәге башка мөлкәтне хосусыйлаштыруга әзерләү буенча чараларны тормышка ашыра.

Хосусыйлаштыру максатыннан чыгып, Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне һәм җир кишәрлекләрен бәяләүне оештыра, шулай ук Татарстан Республикасының мөлкәткә хокукларын һәм башка хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен хәл итә, бәяне раслый һәм хосусыйлаштырыла торган предприятиеләрнең устав капиталы күләмен билгели.

3.3.44. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килешенеп, Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне (предприятиеләрнең акцияләре, өлешләре, пайлары, мөлкәт комплекслары) хосусыйлаштыру турында, шул исәптән аны хуҗалык итүче җәмгыятьләрнең устав капиталына кертем сыйфатында кертү турында, Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыру планнарын раслау турында карарлар кабул итә. Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында күздә тотылган очракларда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан тиешле карарлар кабул итү өчен тәкъдимнәр әзерли.

3.3.45. Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыру турында, шулай ук хосусыйлаштыруның алыш-биреш нәтиҗәләре турында мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларны бастыруны тәэмин итә.

3.3.46. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең кызыксынулы органнары белән берлектә Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне һәм җир кишәрлекләрен сату буенча конкурслар шартларын эшли.

3.3.47. Татарстан Республикасы исеменнән, ачык акционерлык җәмгыятьләренең, шул исәптән дәүләт предприятиеләрен һәм Татарстан Республикасы дәүләт милкен хосусыйлаштыру процессында оештырыла торган ачык акционерлык җәмгыятьләренең гамәлгә куючысы (катнашучы), шулай ук закон нигезендә Татарстан Республикасы катнашында оештырыла торган башка юридик затларның гамәлгә куючысы була.

Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыру процессында оештырыла торган хуҗалык итүче җәмгыятьләрнең уставларын раслый.

3.3.48. Хосусыйлаштыру процессында оештырыла торган ачык акционерлык җәмгыятьләренә карата махсус хокуктан (“алтын акция”) файдалану турында яки аны юкка чыгару турында карар кабул итә.

3.3.49. Татарстан Республикасы исеменнән, закон нигезендә, акцияләре (устав капиталындагы өлеше) Татарстан Республикасы милкендә булган акционерлык җәмгыятьләренең (хуҗалык итүче җәмгыятьләр) акционер (катнашучы) хокукын хәл итә.

“Акционерлык җәмгыятьләре турында” Федераль законда билгеләнгән очракларда устав капиталларында Татарстан Республикасы өлеше булган акционерлык җәмгыятьләрендә зур алыш-бирешләрне һәм кызыксыну тудырган алыш-бирешләрне хуплау турында карар кабул итә.

3.3.50. Тавыш бирүче барлык акцияләре Татарстан Республикасы милкендә булган акционерлык җәмгыятьләрендә акционерларның гомуми җыелышы вәкаләтләрен хәл итә.

3.3.51. Үткән ел өчен Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыру нәтиҗәләре турында хисап әзерли һәм аны билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына һәм вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына тапшыра.

3.3.52. Стратегик дәүләт предприятиеләре һәм акционерлык җәмгыятьләре исемлеген формалаштыру турында, шулай ук әлеге исемлеккә үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр әзерли.

3.3.53. Үз компетенциясе чикләрендә, устав капиталларында Татарстан Республикасы өлеше булган хуҗалык итүче җәмгыятьләрнең идарә һәм контрольлек органнарына, акционерларның гомуми җыелышларында сайлау өчен, Татарстан Республикасы вәкилләре кандидатураларын тәкъдим итә, Татарстан Республикасы үзләренә карата махсус хокук (“алтын акция”) кулланган хуҗалык итүче җәмгыятьләрнең идарә һәм контрольлек органнарына Татарстан Республикасы вәкилләрен билгели. Аларны укыту-өйрәтүне, методик яктан тәэмин итүне һәм аларның эшчәнлегенә контрольлек итүне оештыра, дәүләти гражданлык хезмәткәрләре булып тормаучы Татарстан Республикасы вәкилләре белән Татарстан Республикасы мәнфәгатьләреннән чыгып эш итүгә тиешле килешүләр төзи. Татарстан Республикасы профессиональ вәкилләре институтын үстерүне тәэмин итә.

3.3.54. Татарстан Республикасы вәкилләренә, билгеләнгән тәртиптә, хуҗалык итүче җәмгыятьләрнең идарә органнарында карарлар проектларын

һәм закон нигезендә күздә тотылган очракта аларның тавыш бирүләрен килештерә. Татарстан Республикасы вәкилләренең, үзләрен билгеләгән дәүләт хакимияте органнары белән килештереп, идарә мәсьәләләре буенча тавыш бирүдә позицияләрен ни дәрәҗәдә үтәүләрен контрольдә тота.

3.3.55. Татарстан Республикасында торак сәясәтен эшләүдә һәм тормышка ашыруда, торак фонды белән, шул исәптән төгәлләнмәгән төзелеш объектлары белән һәм Татарстан Республикасы милкендәге күп фатирлы йортлардагы торак белән идарә итү системасын булдыруда катнаша.

Торакны социаль, коммерциячел торак фонды, махсус торак фонды составына кертү һәм чыгару мәсьәләләре буенча карарлар кабул итә.

Татарстан Республикасы милкендәге, гражданнарга социаль, коммерция наймы килешүләре буенча бирелгән торакны учетка алу системасын оештыра.

Торак милекчеләре ширкәтләрен һәм башка формалардагы торак милекчеләре берләшмәләрен оештыру процессларын һәм аларның эшчәнлеген методик яктан тәэмин итүне хәл итә.

Татарстан Республикасы милкендәге торак фонды объектларын махсус оешмаларга һәм идарәче оешмаларга хуҗалык алып баруга, оператив идарәгә, бушлай файдалануга һәм башка төрле идарәгә тапшыра.

3.3.56. Татарстан Республикасы казна милкен тәшкил итүче торакны социаль, коммерция наймына тапшыру турында карарлар кабул итә, торакка социаль, коммерция наймы килешүләре төзи.

3.3.57. Татарстан Республикасы дәүләт торак фондын хосусыйлаштыруны оештыра.

Татарстан Республикасы социаль дәүләт торак фонды торагын үз ирекләре белән биләгән гражданнарга торакны милеккә бушлай тапшыру килешүләрен төзүне хәл итә.

3.3.58. Татарстан Республикасы милкендәге халык өчен күчемсез милек белән идарә итүдә Татарстан Республикасы социаль-икътисадый вазыйфаларын үтәүне һәм Татарстан Республикасы милкендәге коммерциячел күчемсез милектән, аны саклау һәм капитализацияләү шартларында, максималь керем алуны тәэмин итә.

3.3.59. Бюджет процессы кысаларында дәүләт милкен, шул исәптән җир ресурсларын сатудан, алардан файдаланудан средстволар кеременә мониторинг һәм һәр объект буенча фаразлауны хәл итә.

3.3.60. Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне һәм җир кишәрлекләрен сатудан, алардан файдаланудан кергән средстволар ягыннан Татарстан Республикасы бюджетының керемнәр администраторы булып тора.

3.3.61. Татарстан Республикасы милкендәге акционерлык җәмгыятьләре акцияләре буенча дивидендларны (башка хуҗалык итүче җәмгыятьләре устав капиталындагы өлешләр буенча керемнәр) Татарстан Республикасы бюджетына күчерү буенча чаралар күрә һәм күчерүгә контрольлек итә.

3.3.62. Дәүләт предприятиеләренең чиста табышының бер өлешен Татарстан Республикасы бюджетына күчерүне оештыра.

Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне һәм җир кишәрлекләрен сатудан һәм арендага бирүдән, шулай ук башкача файдаланудан кергән средстволарның Татарстан Республикасы бюджетына алынуына контрольлек итә.

3.3.63. Дәүләт предприятиеләрен реформалау, Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне һәм җир ресурсларын хосусыйлаштыру, алар белән идарә итү һәм эш итү процессларын методик һәм хокукый яктан тәэмин итә.

3.3.64. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең кызыксынулы органнары катнашында Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт белән идарә итү, эш итү, аны хосусыйлаштыру, Татарстан Республикасы милкендәге җир ресурслары белән идарә итү һәм җир, милек мөнәсәбәтләрен, җир базарын һәм күчемсез милек базарын дәүләти җайга салу, Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәттән файдалануга контрольлек итү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив-хокукый актлар проектлары эшли.

3.3.65. Җирле үзидарә органнарына муниципаль берәмлекләр милкендәге мөлкәт һәм җирләр белән идарә итү, алар белән эш итү мәсьәләләрендә, шул исәптән Татарстан Республикасында муниципаль милекне формалаштыру процессларын тәэмин итү буенча норматив-хокукый актлар проектларын, муниципаль берәмлекләр милкендәге мөлкәт һәм җирләр белән идарә итү, эш итү һәм милек, җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә җирле үзидарә органнары тарафыннан дәгъва эшләрен алып бару мәсьәләләрендә практик һәм методик ярдәм күрсәтә.

3.3.66. Закон нигезендә җирле үзидарә органнарының милек базасын формалаштыру буенча чаралар оештыра һәм аларны тормышка ашыра.

Җирле үзидарә органнары белән Татарстан Республикасы күчемсез милек һәм җир базары инфраструктурасы оешмаларының берлектә эшләвен тәэмин итә.

3.3.67. Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт һәм җир ресурслары белән идарә итү буенча тапшырылган кайбер Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан үтәлүенә контрольлек итә (тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен хәл итү сыйфатын чагылдыручы индикаторлар билгеләү һәм индикаторлар күрсәткечләренә ирешүгә контрольлек итү юлы белән).

3.3.68. Җир һәм милек мөнәсәбәтләрен җайга салу мәсьәләләре буенча тармак компетенциясендәге һәм махсус компетенциядәге Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, дәүләт предприятиеләре һәм дәүләт учреждениеләре эшчәнлегенә методик җитәкчелек итүне һәм эшчәнлеген координацияләүне хәл итә.

3.3.69. Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәттән, җир кишәрлекләреннән һәм үзләренә карата дәүләт милке чикләре билгеләнмәгән җир кишәрлекләреннән файдалануга аренда түләве күләмен билгеләү, шулай

ук җир кишәрлекләреннән файдалануга аренда түләвен кертү тәртибен, шартларын һәм срокларын билгеләү буенча тәкъдимнәр эшли һәм аларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшыра.

3.3.70. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм тармак компетенциясендәге Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең тиешле органы белән үзара килешенеп:

дәүләт предприятиеләре җитәкчеләрен сайлый, вазыйфага билгели, вазыйфасыннан ала;

дәүләт предприятиеләре җитәкчеләре белән хезмәт килешүләре төзи, аларны үзгәртә һәм өзә (шул исәптән элегрәк тармак министрлыклары тарафыннан төзелгән хезмәт килешүләрен), закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә хезмәт килешүләре шартларын үтәүгә контрольлек итә.

Дәүләт предприятиеләренең баш бухгалтерларын эшкә алуны килештерә, алар белән хезмәт килешүе төзи, хезмәт килешүен үзгәртә һәм туктата.

3.3.71. Дәүләт предприятиеләре җитәкчеләре белән төзелгән хезмәт килешүләре, ышаныч нигезендә идарә итү, концессия, аренда, залог килешүләре, инвестицион килешүләр һәм Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт белән башкача эш итү килешүләре, акцияләре (өлешләре, кертемнәре) Татарстан Республикасы милкендә булган акционерлык җәмгыятьләренең (хуҗалык итүче җәмгыятьләр) органнарында Татарстан Республикасы мәнфәгатьләреннән чыгып эш итүгә килешүләр учетын (реестр) алып бара, аларның шартларын үтәүгә контрольлек итә.

3.3.72. Татарстан Республикасы исеменнән, үз компетенциясе чикләрендә, Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе территориясендәге һәм чит илдәге Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәткә карата Татарстан Республикасының милеккә хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итә.

Татарстан Республикасының милеккә хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау максатыннан чыгып, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең дәүләт органнары һәм башка органнары белән берлектә эшли.

3.3.73. Банкротлык турында эшләрдә һәм бөлгенлек процедураларында:

акчалата йөкләмәләр буенча Татарстан Республикасы таләпләреннән;

бурычлылар – Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре мөлкәтенең милекче мәнфәгатьләреннән чыгып эш итә;

устав (җыелма) капиталларында Татарстан Республикасы өлеше (кертем) булган хуҗалык итүче җәмгыятьләрнең гамәлгә куючылары (катнашучылар) мәнфәгатьләрен яклый;

бөлгенлек турында эштә кулланыла торган процедураларда Татарстан Республикасының башка мөлкәти мәнфәгатьләрен яклый.

Татарстан Республикасы дәүләт предприятиеләренең һәм устав (җыелма) капиталларында Татарстан Республикасы өлеше (кертем) булган хуҗалык итүче җәмгыятьләрнең кредиторлары җыелышларында катнашуы

өчен Татарстан Республикасы вәкилләрен билгели. Аларны укыту-өйрәтүне, методик яктан тәэмин итүне һәм аларның эшчәнлегенә контрольлек итүне оештыра.

3.3.74. Законда күздә тотылган тәртиптә һәм шартларда, тиешле норматив-хокукый актлар яки килешүләр нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендәге федераль милеккә карата милекче вәкаләтләрен тормышка ашыра.

3.3.75. Устав капиталларында Татарстан Республикасы өлеше булган акционерлык җәмгыятьләренә акцияләр базарын үстерүгә, аларны Россия сәүдә мәйданчыкларына һәм башка сәүдә мәйданчыкларына чыгаруга методик ярдәм күрсәтә.

3.3.76. Министрлыкның, эшчәнлекләре Министрлык эшчәнлеге белән бәйле яки аның карамагы өлкәсендәге оешмаларның мобилизацион әзерлеген һәм мобилизациясен, әлеге чараларның методик тәэмин ителешен оештыра һәм тәэмин итә.

**4. Министрлык хокуклары һәм бурычлары**

4.1. Министрлык хокуклы:

4.1.1. Үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне идарә итүгә (шул исәптән учетка алу), аның белән эш итүгә, хосусыйлаштыруга, Татарстан Республикасы җир ресурслары белән идарә итүгә һәм җир, милек мөнәсәбәтләрен һәм күчемсез милек базарын җайга салу, Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәттән файдалануга контрольлек итү мәсьәләләре буенча норматив-хокукый актлар чыгаруга, шулай ук бу мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирүгә.

4.1.2. Үз исеменнән алыш-бирешләр ясауга, закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә мөлкәти һәм мөлкәти булмаган хокуклар алуга, җаваплылык тотуга, судта дәгъвачы һәм җавап бирүче буларак чыгуга.

4.1.3. Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт белән идарә итү буенча үзенең вәкаләтләренең бер өлешен (милекне һәм җир кишәрлекләрен хосусыйлаштырудан, алар белән эш итү, Татарстан Республикасы вәкилләрен билгеләү, уставлар раслау, хезмәт килешүләрен килештерүдән тыш) тормышка ашыруны башка Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына йөкләүгә.

4.1.4. Устав капиталларында Татарстан Республикасы өлеше булган акционерлык җәмгыятьләрнең акционерлар җыелышларының һәм Директорлар советларының көн тәртибенә тәкъдимнәр җибәрүгә, аларны үткәрүгә контрольлек итүгә.

4.1.5. Җир кишәрлекләрен тартып алу һәм бирү мәсьәләләре буенча, җир мөнәсәбәтләре белән бәйле башка мәсьәләләр буенча җирле үзидарә органнарының хокукка каршы карарларын юкка чыгару турында тәкъдимнәр кертүгә.

4.1.6. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарыннан, дәүләт предприятиеләреннән һәм дәүләт учреждениеләреннән, җирле үзидарә органнарыннан, хуҗалык итүче җәмгыятьләрдән, Татарстан Республикасы

территориясендәге башка оешмалардан, закон нигезендә, икътисадый, статистик, хокукый мәгълүмат һәм Министрлыкка йөкләнгән бурычларны үтәү өчен кирәкле башка мәгълүмат алуга.

4.1.7. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасындагы идарәсеннән җир кишәрлекләренә һәм күчемсез милек объектларына хокуклар турында һәм алар белән алыш-бирешләр турында мәгълүматны, Татарстан Республикасы милкендәге җирләр белән идарә итүне оештыру, мөлкәтне учетка алу һәм аның реестрын алып бару өчен кирәкле башка мәгълүматларны закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә бушлай сорап алуга.

4.1.8. Татарстан Республикасы исеменнән судларга дәгъвалар (гаризалар) белән мөрәҗәгать итүгә:

өч ел дәвамында тиешенчә файдаланылмаган очракта яки билгеләнеше максатына туры китерелмичә файдаланылган очракта, авыл хуҗалыгы максатындагы җирләрдәге җир кишәрлеген милекчесеннән мәҗбүри төстә алу мәсьәләләре буенча;

устав (җыелма) капиталларында Татарстан Республикасы өлеше (кертем) булган дәүләт предприятиеләренә һәм хуҗалык итүче җәмгыятьләргә карата бөлгенлек процедураларын хәл итү процессында закон бозу нигезендә хәл ителгән алыш-бирешләрнең гамәлдә түгеллеген тану мәсьәләләре буенча;

Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыру, аның белән идарә итү һәм эш итү мәсьәләләре буенча дәүләт мәнфәгатьләрен яклауга:

Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыру һәм аның белән эш итү буенча алыш-бирешләрнең гамәлдә түгеллеген тануга;

дәүләт предприятиеләре табышының бер өлешен түләтүгә;

аренда түләүләре алу һәм Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәттән һәм җир кишәрлекләреннән файдалану өчен башка түләүләр алуга;

физик һәм (яки) юридик затларның хокукка каршы гамәлләре аркасында Татарстан Республикасына китерелгән зыянны һәм башка төрле зыяннарны каплауга;

закон нигезендә күздә тотылган очракларда башка мәсьәләләр буенча.

4.1.9. Татарстан Республикасы милкендә булып, оешмаларга хуҗалык алып бару, оператив идарә, ышаныч нигезендә идарә итү хокукында билгеләнгән милекне, закон нигезендә билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә тартып алуга.

4.1.10. Министрлык карамагындагы дәүләт учреждениеләренә карата:

уставлары нигезендә эшчәнлекләренең предметларын һәм максатларын билгеләүгә, расланган дәүләт хисабы формалары нигезендә эшчәнлекләренә анализ ясау һәм финанс-хуҗалык эшчәнлегенә контрольлек итүгә, Татарстан Республикасы милкендә булып, оператив идарәгә тапшырылган мөлкәтнең учетына, сакланылышына һәм керемена контрольлек итүгә;

Министрлык карамагындагы дәүләт учреждениеләре җитәкчеләрен вазыйфага сайлауны, билгеләү, раслауны, вазыйфадан азат итүне, хезмәт килешүләрен төзүне, үзгәртү һәм өзүне закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә хәл итүгә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә вазыйфасына билгеләнелә һәм вазыйфасыннан азат ителә торган дәүләт учреждениеләре җитәкчеләренең хезмәт килешүләреннән тыш;

дәүләт учреждениеләре җитәкчеләренең закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә хезмәт килешүләре шартларын үтәвенә контрольлек итүгә.

4.1.11. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ризалыгы белән һәм гамәлдәге закон нигезендә дәүләт предприятиеләрен, дәүләт учреждениеләрен, аларның филиалларын һәм вәкиллекләрен оештыруга.

4.1.12. Норматив-хокукый актлар проектларын эшләү, Министрлык компетенциясенә керүче аерым мәсьәләләрне хәл кылу өчен түләүле нигездә фәнни учреждениеләрне, югары уку йортларын, аудиторлык, консалтинг һәм башка оешмаларны, шулай ук аерым галимнәрне, белгечләр, экспертларны җәлеп итүгә.

4.1.13. Проект-тикшерену, фәнни-тикшерену һәм җир реформасы, җир ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану белән бәйле башка эшләрнең дәүләт заказчысы сыйфатында чыгуга, закон нигезендә аларны үтәүгә заказлар урнаштыруга.

4.1.14. Закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт һәм җир ресурслары белән идарә итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында тәкъдимнәрне закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә кертүгә.

4.1.15. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Министрлык тарафыннан әзерләнгән хокукый актлар проектларына яки алар тарафыннан бастырып чыгарылган хокукый актларга коррупциягә каршы экспертиза үткәрү турында тәкъдимнәр кертүгә.

4.2. Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүче дәүләти гражданлык хезмәткәрләре Министрлык җитәкчелеге билгеләгән очракта һәм тәртиптә, хезмәт таныклыкларын күрсәтеп, устав капиталларында Татарстан Республикасы өлеше булган дәүләт предприятиеләренә һәм дәүләт учреждениеләренә һәм оператив, ышаныч нигезендә идарә итү хокукында һәм хуҗалык алып бару өчен бирелгән, шулай ук арендага бирелгән Татарстан Республикасы милкенә ия булучы башка хуҗалык итүче субъектларга комачаулыксыз үтүгә хокуклы.

4.3. Министрлык бурычлы:

4.3.1. Үз компетенциясе чикләрендә, Татарстан Республикасының икътисадый мәнфәгатьләренә зыян китермичә, Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт һәм җир ресурслары белән нәтиҗәле идарә итүгә.

4.3.2. Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруда закон бозу очрагында мөлкәтне хосусыйлаштыру буенча

алыш-бирешне өзүгә, зыянны түләтүгә һәм, Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне сату-алу килешүләре һәм закон нигезендә, башка чаралар куллану турында суд тәртибендә дәгъвалар белдерүгә.

4.3.3. Коррупцион хокук бозуларны кисәтү буенча чаралар күрүгә, ведомствоның коррупциягә каршы программаларын эшләүгә, билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле органнарга җир мөнәсәбәтләре, шулай ук Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәткә ия булу, аннан файдалану һәм аның белән эш итү өлкәләрендә закон бозулар турында материалларны, гаепле затларны җаваплылыкка тарту турында карарлар кабул итү өчен, билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле органнарга җибәрүгә.

4.3.4. Закон нигезендә, Министрлыкның эшчәнлеге процессында хасил булган архив документларын комплектлауга, саклау, учетка алу һәм алар белән эш итүне хәл итәргә.

**5. Министрлык эшчәнлеген оештыру**

5.1. Министрлыкка министр җитәкчелек итә. Ул Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә билгеләнгән тәртиптә вазыйфасына билгеләнелә һәм вазыйфасыннан азат ителә.

Министр урынбасарлары, министр тәкъдиме белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә вазыйфасына билгеләнелә һәм вазыйфасыннан азат ителә.

5.2. Министр:

Министрлык эшен оештыра;

башка дәүләт башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган оешмалар, учреждениеләр, предприятиеләр белән үзара мөнәсәбәтләрдә Министрлык исеменнән эш итә;

үзенең урынбасарлары арасында бурычлар билгели, шулай ук Министрлык аппаратының структур подразделение җитәкчеләре вазыйфаларын билгели;

Министрлыкның үз компетенциясенә кергән вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен үтәвенә һәм Министрлык тарафыннан кабул ителә торган хокукый актларның һәм аның тарафыннан оештыру-боеру гамәлләренең законлылыгына персональ җавап бирә;

Министрлыкның, аның структур подразделениеләренең эшчәнлеген, шулай ук аның карамагындагы дәүләт предприятеләренең, дәүләт учреждениеләренең, оешмаларның эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча хокукый актлар чыгара.

үз компетенциясе чикләрендә боерыклар чыгара, аларның үтәлешен контрольдә тотуны оештыра;

билгеләнгән чикләрдә хезмәткәрләр санын, хезмәткә түләү фондын һәм бюджет ассигнованиеләрен, штат расписаниесен, Министрлык аппаратын тоту чыгымнары сметасын раслый;

Министрлык структурасына керүче подразделениеләр турында нигезләмәләрне, шулай ук Министрлык тарафыннан оештырыла торган

дәүләт предприятиеләре һәм учреждениеләре уставларын яки башка норматив актларын раслый;

Министрлык хезмәткәрләрен вазыйфага билгели һәм вазыйфадан азат итә;

закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда дәүләт предприятиеләре һәм учреждениеләре җитәкчеләрен вазыйфага билгели һәм вазыйфадан азат итә.

5.3. Министрлыкта, билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә мөһим бурычларны үзара килештереп хәл итү өчен, министрдан (коллегия рәисе), аның урынбасарларыннан (коллегия составына вазыйфасы буенча керүче), шулай ук башка затлардан, шул исәптән Министрлыкның структур подразделениеләре, ведомство карамагындагы оешмалар җитәкчеләреннән коллегия оештырылырга мөмкин. Коллегия составына шулай ук Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары вәкилләре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, коммерцияле һәм коммерциясез оешмалар җитәкчеләре, галимнәр һәм белгечләр керергә мөмкин.

Коллегия составы һәм аның әгъзалары саны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә раслана.

Коллегиянең төп бурычы булып җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә дәүләт идарәсе вазыйфаларын хәл кылуга бәйле мөһим мәсьәләләр буенча чишелешләр табу тора.

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәгә кушымта**

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының предприятиеләр һәм оешмалар белән берлектәге икътисадый эшчәнлеге төрләре исемлеге**

| ОКВЭД <*> | Икътисадый эшчәнлек төрләре атамасы |
|---|---|
| 70.1 | Үзенең күчемсез милкен сатуга әзерләү, күчемсез милек сатып алу һәм сату |
| 70.11 | Үзенең күчемсез милкен сатуга әзерләү |
| 70.11.1 | Үзенең күчемсез торак милкен сатуга әзерләү |
| 70.11.2 | Үзенең торак булмаган күчемсез милкен сатуга әзерләү |
| 70.12 | Үзенең күчемсез милкен сату һәм күчемсез милек сатып алу |

| | |
|---|---|
| 70.12.1 | Үзенең күчемсез торак милкен сату һәм күчемсез милек сатып алу |
| 70.12.2 | Үзенең торак булмаган биналарын һәм бүлмәләрен сату һәм торак булмаган биналарны һәм бүлмәләрне чатып алу |
| 70.12.3 | Җир кишәрлекләрен сатып алу һәм сату |
| 70.2 | Үзенең күчемсез милкен наймга тапшыру |
| 70.20 | Үзенең күчемсез милкен наймга тапшыру |
| 70.20.1 | Үзенең күчемсез торак милкен наймга тапшыру |
| 70.3 | Күчемсез милек белән бәйле арадашчылык хезмәтләре күрсәтү |
| 70.31 | Күчемсез милек белән операцияләр буенча агентлыклар эшчәнлеге |
| 70.31.1 | Күчемсез милекне сатып алуда, сату һәм арендага бирүдә арадашчылык хезмәтләре күрсәтү |
| 70.31.11 | Күчемсез торак милкен сатып алуда, сату һәм арендага бирүдә арадашчылык хезмәтләре күрсәтү |
| 70.31.12 | Торак булмаган күчемсез милекне сатып алуда, сату һәм арендага бирүдә арадашчылык хезмәтләре күрсәтү |
| 70.31.2 | Күчемсез милекне бәяләүдә арадашчылык хезмәтләре күрсәтү |
| 70.31.21 | Күчемсез торак милкен бәяләүдә арадашчылык хезмәтләре күрсәтү |
| 70.31.22 | Торак булмаган күчемсез милекне бәяләүдә арадашчылык хезмәтләре күрсәтү |
| 71.3 | Машиналар һәм җиһазлар арендалау |
| 74.12.2 | Аудиторлык эшчәнлеге |
| 74.20.36 | Җир үлчәү-ызанлау эшләре |

---

<*> Россия Федерациясе Стандартлаштыру һәм метрология дәүләт комитетының 06.11.2001 ел, № 454-ст карары белән расланган Икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы нигезендә икътисадый эшчәнлек төрләре кодларының билгеләнеше